**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ҖӨРИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**Дүртенче чакырылышның уналтынчы утырышы**

01.04.2022 ел №57 Иске Җөри ав.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Иске Җөри авыл җирлегенең
генераль планын әзерләү кирәк
булмау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Иске Җөри авыл җирлеге территориясендә җирлек территориясен куллануны үзгәртү каралмауга, комплекслы социаль-икътисадый үсеш программасы булмауга, Татарстан Республикасын һәм Теләче муниципаль районын территориаль планлаштыру схемаларына , федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру каралмауга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге Советы карар итте,

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлегенең генераль планын әзерләү кирәк булмавын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр танырга.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 10 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Әлеге карарны Теләче муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Теләче
муниципаль районының Иске Җөри
авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Мараков